«ВАКЫТ ИНДЕ: без дә торыйк, ирек алыйк...»

(Бөтенрусия мөслимәләр съездына 90 ел)

Һәр тугрыда ким түгелбез ирләрдән без,
Гыйлем алсак, иң галимнәренә тиң без.
Бер милләтнең там ярты-
сы без булгачтын,
Карап карыйк: ирәнләрдән ничек ким без?!
Маһруй Мозаффария.

Патша хакимиятен юкка чыгарган 1917 елгы февраль революциясе, русиялеләргә яңа офыклар ачып, бик күпләргә иң яшерен теләкләрен, киң өметләрен тормышка ашыру мизгеле килеп җиткәнлеген күрсәткән. Берничә айга Русия ирекле илгә әйләнгән. Бөтен ил, әлбәттә, татар җәмгыяте дә, ифрат зур үзгәрешләр кичергән чор бу. Татарлар күпләп яшәгән Казан, Уфа, Әстерхан, Оренбург, Мәскәү, Петроград, Троицк һәм башка шәһәрләрдә генә түгел, хәтта авылларда да төрледән-төрле милли иҗтимагый-сәяси оешмалар барлыкка килгән. Митинг, демонстрация, корылтай-съездларның исәбе-хисабы булмаган. Бөтен Русиядәге кебек, татарлар да чорның иң мөһим сәяси мәсьәләләрен көн үзәгендә тотканнар: сугыш һәм солых, демократик республика һәм Учредительный собрание, милләтләр арасында тигез хокуклылык һәм үзбилгеләнү һ. б... Бу чараларның бик күпләрендә хатын-кызлар да актив катнашкан һәм үз хакларын яуларга керешкән.

Хакимият алмашынудан соң беренчеләр булып Мәскәү мөслимәләре кузгалган. 5 мартта ук җыелыш уздырып, алар Дәүләт думасының мөселман фракциясенә телеграмма юллаганнар. «Мәскәүдәге мөселман хатын-кызлары яңа хөкүмәтне тәбриклиләр һәм хатыннар өчен сәяси вә гражданский хокуклар да таләп итәләр»[1], — дигән сүзләр була анда. Димәк, революция җиңгәннең беренче көннәрендә үк татар хатын-кызлары мөслимәләрнең хокукы таләбен куйган. Җыелыш хакындагы хәбәрне, кабул ителгән карарлары белән бергә, мәскәүлеләр төрле газета-журналларга җибәргәннәр. Мөрәҗәгатьләрендә алар башка төбәк хатын-кызларын да эшкә чакырганнар: «Мәскәү хатын-кызлары кебек Казан, Уфа, Оренбург, Троицки, Әстерхан шәһәрләре хатын-кызлары да ничә гасырлардан бирле тапталган хокукларын сорарлар дип өмет итәбез... Аурупа хатын-кызларына күз салып, алардан гыйбрәт алырга кирәк. Алар дөньяның иң хөр, иң иреклеләре булсалар да, үзләре турындагы законнарны бик зарарлы, хәтта кимсетү нигезенә корылган дип табалар»[2]. Бу материаллардан мөслимәләрнең рус феминистик оешмаларының тәжрибәсеннән, документларыннан файдаланулары сизелә. Йогынты, аеруча, алар хәзерләгән таләпләрдә ачык күренә.

Хатын-кыз хокукларын мәскәүлеләр түбәндәгечә билгеләгәннәр:

«1. Хатын-кызга гражданлык һәм сәяси хокукларның һәммәсе бирелергә тиеш (моңа ирешү өчен “гражданлык”, “хокук” гыйбарәләре янына максудны ачык белдерү өчен “һәр ике төркемгә, ягъни ирләр вә хатыннарга” дигән сүз арттырылсын).

2. Хатын-кызга хезмәт бәһасе ирләрнеке белән бертигез ителсен. Аналар һәм балалар хакларын саклау кагыйдәләре урнаштырылсын.

3. Киләчәктә ирләр эшләрен ислах кылганда, хатын-кызлар ирләр белән бертигез хокукта йөртелсен.

4. Хатын-кызның адәмлек шәрәфен кимсетә торган вәхшилек законнар бетерелсен.

5. Дахилия (эчке эшләр), гадлия (юстиция), мәгариф, сәүдә вә һөнәр һәм җир эшләре министрлыкларында хәзер үк хатын-кызлардан торган комиссияләр төзелсен. Бу комиссияләр хатын-кызларга караган мәсьәләләрне, эшләрне башкарып торсын.

6. Һәммә шәһәрләрдә һәм авылларда хәзердән үк хатын-кыз комиссарлар куелсын. Алар дәүләт һәм җәмәгать эшләрен эшли башласыннар.

7. Хатын-кызга фабрикалар инспекциясендә, адвокатлыкта, нотариуслыкта һәм башка җәмәгать эшләрендә хезмәт кылуга ирек бирелсен.

8. Әгәр дә Русия чынлап та азат бер мәмләкәт булса, бу таләпләр һич тоткарсыз үтәлсеннәр. Үтәлмиләр икән, “азат гражданнар” дигән сүзнең ирләргә генә икәнлеген, хатын-кызның әүвәлгечә үк хокуксыз хәлдә калдырылганы ачыктан-ачык әйтелсен»[3].

1917 елның март-апрель айлары — Русиянең төрле төбәкләрендә яшәгән татар хатын-кызлары хәрәкәткә килә башлаган чор. Казан, Оренбург, Уфа, Троицк, Әстерхан һәм башка күп кенә шәһәр һәм авылларда мөслимәләр җыелышлары оештырылган. Аларның барысында да хатын-кыз азатлыгы, тигез хокуклык, аны даулау өчен берләшү, яңа шартларда туган мөмкинлекләрдән файдалану, ниһаять, хатын-кыз ихтыяҗларын барлап, Русия мөселманнары съездына бердәм программа хәзерләү өчен Бөтенрусия мөслимәләре съездын уздыру зарурилыгы кебек мәсьәләләр куелган. Еш кына әле оештыру эшләре дә башланмаган съездга вәкиләләр дә сайланган.

Казан вакыйгаларына тукталыйк, чөнки нәкъ алар татар хатын-кыз хәрәкәтенең бу чорда ничек тиз формалашуын да, казанлыларның үз шәһәрләрен Русия мөслимәләрен берләштерү үзәгенә, хатын-кыз хокуклары өчен көрәш мәйданына әверелдерүен дә ачык күрсәтә.

13 мартта (ягъни әле патша хакимияте җимерелеп ун көн генә узган була) Ф. Аитова кызлар гимназиясе бинасына җыелган 71 мөгаллимә һәм учительница (болары рус-татар һәм башка мәктәпләрдә русча укытучылар), яңа мөмкинлекләрне күздә тотып, берләшү һәм милләт файдасына хезмәт итү юллары хакында сөйләшкәннәр. Биш сәгать дәвамында алар гимназия мөгаллимәләре М. Акимбәтева (соңгы революция һәм яңа хөкүмәт), М. Мөштәриева (конституция, җөмһүрият, Учредительный собрание), М. Сәгыйтова (Русиядә революцион хәрәкәт тарихы), С. Таһирова (иске хакимиятнең татарларга каршы сәясәте) һәм башкаларның тәфсилле чыгышларын тыңлап, үзара ярдәмләшеп эшләү өчен мөслимә укытучылар җәмгыяте оештыру хакында карар да кабул иткәннәр.

Җәмгыятьнең максаты — Казан һәм Казан губернасындагы мөслимә укытучыларны берләштерү, аларга матди һәм мәгънәви ярдәм оештыру. Аның идарәсенә рәисә итеп атаклы Казан мөгаллимәсе Л. Хөсәенова сайланган, аңа ярдәмгә Ә. Галиева белән М. Гобәйдуллина билгеләнгән. 7 мартта оешкан Мөселман комитетына да ике вәкилә (теш табибәсе Х. Таначева һәм гимназия директоры М. Акимбәтеваны) җибәрергә булганнар. Җәмгыятькә һәр мәктәп берәр вәкилә сайлап җибәрергә тиеш дигән карар да кабул ителгән. Җыелыш һәм мөслимә укытучылар җәмгыяте оештыру хакында матбугатта хәбәр урнаштырылган. «Чын эш, чын куәт берләшү берлә генә буладыр. Шунлыктан җәмгыять Казан губернасында булган һәр укытучы абыстай вә учительница һәм мөгаллимәләрнең әгъза булып язылуларын бик кирәкле табадыр. Җәмгыятьнең уставы төзелеп тәмам булу белән әгъзаларына күндереләчәктер. Әгъзалык бәдәле (бәясе) өч сум. Җәмгыятьнең адресы: Казань, Екатеринская, дом Алкина, Фатыме Давлеткильдеевой»[4], — дигән өндәмә дә булган анда.

Үз җәмгыятьләрен оештыру белән

бергә, мөслимә укытучылар Казан хатын-кызларын оештыру эшенә дә алынган. 16 мартта «Свет» кинематографы бинасында укытучылар оештырган Казан мөслимәләренең беренче гомуми җыелышы узган. Килүчеләр бик күп булган (урын җитмәү сәбәпле хәтта кайберләре кайтып киткән). Җыелышның рәисәсе — М. Гобәйдуллина һәм тагын унбишләп ханым вә туташ яңа хөкүмәт биргән хокукларны аңлатып чыгышлар ясаган. Мөселман комитетына ике вәкилә сайлауга кайтып, җыелыш Х. Таначева һәм Г. Юнысованы (М. Акимбәтева урынына) сайлаган. Җыелыш ахырында мөслимәләр җәмгыятенә кабул итү игълан ителгән. Икешәр сум түләп бик күп хатын-кыз әгъзалыкка язылу белән бергә, булачак җәмгыять исеменә иганә дә җыелган (өч сумнан мең сумга кадәр бирүчеләр булган). «Гомуми мәҗлес бик рухлы вә бик ямьле үтте. Яңа хөкүмәтнең хокукта тигез мөслимәләре вакытның әһәмиятлелеген вә берләшеп, кулкулга тотышып, мөмкин кадәр тиз, дәрт вә нишан (максат) белән эшкә керешү өстендәге бурыч икәнлеген бу дәрәҗә төшенә башлаганнар икән...»[5], — дип тәмамлаган «Кояш» газетасында бу вакыйга хакындагы хәбәрен Х. М. (гимназия мөгаллимәсе Хәдичә Мостафина булса кирәк. — *А. М.*).

Ике җәмгыять тә бергәләшеп, эшкә бик актив тотынган: җәмгыятьләрне оештыру мәсьәләләреннән тыш алар төрле митинглар, җыелышлар, курслар уздырган. Мисал өчен шундый чараларның берсе хакында «Кояш» газетасында бирелгән хәбәрне алыйк. «Казан мөгаллимәләр вә мөслимәләр җәмгыяте хатын-кызлар өчен фикер тарату курслары ачарга карар бирде. Курсларның төп максаты — Казан вә әтрафындагы ханымнарны хәзерге хәл белән таныштырырлык вә Учредительный собраниегә сайлауларга хәзерләрлек ханымнар җитештерүдер. Уку унынчы апрельдә башланып, мөддәте ун көн булачак. Үзен шул эшкә икътидарлы (сәләтле) санаган ханым-туташлар хәзердән үк түбәндәге кешеләрдә язылырга тиеш»[6], — дип язылган анда һәм З. Хәсәнова, М. Мөштәриева, Х. Мостафиналарның адреслары китерелгән. Шулай итеп, беренче бурыч булып хатын-кызлар арасында аңлату эшләрен җәелдереп җибәрү каралган.

1 апрельдә мөслимәләр җәмгыятен оештыру комитеты үз әгъзалары арасыннан өч кешедән торган «вакытлы мәркәзи комитет» ясаган. Ул исә, Казан һәм губернасы белән генә чикләнмичә, эшен татарлар яшәгән барлык төбәкләргә таратырга тотынган. «Комитетта эшләшергә Петроград, Мәскәү, Оренбург вә Уфадан вәкиләләр чакырылып, телеграммалар җибәрелде. Вакытлы мәркәзи комитетның максаты — якында булачак мөселман съездына хәтты хәрәкәтләрен хәзерләп кую өчен Русия мөслимәләренең съездын ясау, — дигән хәбәр урнаштырган “Кояш”та комитет. — Бу эшкә бар мөслимәләрнең җитди караулары көтеләдер. Комитет үз ягыннан мөслимәләрне мөмкин кадәр тизрәк берләшергә һәм, һәрбер шәһәрдә оешмалар ясап, хәзердән үк булачак съездга эшлекле вәкиләләр җибәрү һәм докладлар хәзерләү мәсьәләләрен карый башларга чакырадыр»[7].

8 апрельдә В. Ибраһимов йортында узган җыелышта җәмгыятькә язылган 260 әгъзаның 190-ы катнашкан. Монда алар җәмгыятьнең җитәкче органын — идарә сайлаганнар, мәскәүлеләрнең Русия мөслимәләренә юллаган өндәмәсен тикшергәннәр. «Мөслимә кардәш вә ептәшләр! Бу тарихи көннәрдә ханымнарыбызның хәзерге һәм киләчәктәге тормышлары өчен мәйданга чыгып, эшкә тотынығыз! Яңгырдан соң чыккан гөлләр кебек бердәм күтәрелегез! Сугышка һич кичекмәстән чик куярга тырышыгыз!.. — диелгән була анда. — Хәзерге көндә бөтен Русия халкы — русы, яһүде, әрмәне вә башкасы үзара киңәшеп җәмгыятьләр, съездлар ясап, аерым бер фикергә килә, сайлау әзерлеген күрә. Сайлауда, сайлануда ханымнарга ирләр белән бертигез хокук биреләчәк булганга, аларның ханымнары да ирләре кебек үк эшли, хәзерләнә, төрле оешмалар ясый... Безнең дә эшли, эшкә ярый торган көчләребез бар. Фәкать болар бер җиргә, бер фикергә, бер максат астына җыелмаган... Ханымнар арасында чәчелгән көчләрне бергә җыеп, аерым бер юл белән барыр өчен без бергә җыелырга тиеш!»[8].

Җыелышта яшерен тавыш белән унике кешедән торган Казан мөслимәләр җәмгыятенең идарәсе сайланган. Идарәгә Ф. Аитова, Х. Апанаева, М. Акимбәтева, М. Гобәйдуллина, Ф. Дәүләткилдиева, Х. Мостафина, Ә. Мөхетдинова, М. Мөштәриева,

Х. Таначева, С. Таһирова, Ә. Терегулова, З. Хәсәновалар кергән. Үз эшләре белән халык алдында зур абруй казанган бу зыялы ханым вә туташлар Бөтенрусия мөслимәләре съездын хәзерләргә керешкәннәр. Хәзерлек эшләрен барлау һәм оештыру өчен 1 апрельдә ясалган Х. Таначева (рәисә), М. Мөштәриева (сәркятибә), Ә. Терегуловалардан торган Вакытлы мәркәз бюрога Мәскәүдән килеп җиткән И. Туктарова кушылган. Хосусый рәвештә эшләшергә Х. Мостафинаны чакырганнар. Казан мөслимәләренең съездны хәзерләү мәсьәләләренә багышланган махсус җыелышында (14 апрель) бу бюро рәсмиләштерелгән.

Оештыру эшләрендә тәжрибәсе булмаган Вакытлы мәркәз бюро әгъзаларына шактый катлаулы проблемаларны чишәргә туры килгән: кыска гына вакыт эчендә (съездны гомуми мөселман корылтае ачылганчы — 1 майга кадәр уздырырга кирәк булган) төрле төбәкләр белән бәйләнешкә керү, съезд уздырырлык бина табу, докладлар хәзерләү, каралачак мәсьәләләрне, докладчыларны билгеләүдән тыш, вәкиләләрне урнаштыру, ашау-эчү якларын җайлау һ. б. «Уфа, Оренбург вә Петроградтан чакырылган вәкиләләр дә бу көннәрдә килеп җитәрләр дип көтеләдер, — дип хәбәр иткән “Кояш” 13 апрель санында. — Комитет съездга килгән ханымнарны урнаштыру һәм ашау-эчү якларын карау өчен Казан ханымнарыннан үзләре мәгъкуль күргән кешеләрне оештырып бер комитет ясауны Фатиха ханым Аитова һәм Зәйнәп ханым Хәсәновага тапшырды»[9].

Съездга катнашу өчен вәкиләләр өч-дүрт көн алдан җыела башлаган. Вакытлы мәркәз бюро аларга да эш тапкан. Ниһаять, съезд ачыласы көн — 24 апрель килеп җиткән. Тыштан кызыл әләмнәр, эчтән күп санлы революцион шигарьләр, хөрриятка, тигез хокуклы булу өчен көрәшкә, берләшергә өндәгән лозунглар белән бизәлгән Новый клуб залын тулысынча хатын-кызлар биләп алган. Ирләр съезд эшенә катнашмаган; шулай да журналистлар өчен махсус урын куелган була. Бу хакта съездны башыннан ахырына кадәр шуннан күзәткән берничә журналист язмасыннан беләбез. Мәсәлән, «Сөембикә» журналының нашире һәм мөхәррире Я. Хәлили съезд барышы хакындагы күзәтүендә бу хакта да язган.

Бөтенрусия мөслимәләре съезды эшен төрле төбәкләрдән килгән 71 вәкилә катнашында башлап җибәргән. Алардан тыш, Я. Хәлили сүзләре белән әйтсәк, моңа кадәр булмаган вакыйганы «күрү, ишетү өчен тагын өч йөздән артык хатын-кыз килеп, баштан ахырга кадәр ихлас белән»[10] тыңлап утырганнар. Юлдагы тәртипсезлекләр аркасында вакытында килеп җитмәүчеләр дә булган. Шуңа күрә һәр утырышта вәкиләләр саны үзгәреп торган (икенче җыелышта 85 вәкилә, өченчесендә тагын берничә килүче өстәлгән, шул исәптән бакулы С. Якупова белән Ә. Шәфика булуы хәбәр ителгән). Җыеп әйткәндә, съезд эшендә нигездә укытучы, табибә, курсистка һәм башка зыялылардан торган барлыгы йөзгә якын вәкилә һәм Вакытлы мәркәз бюро тарафыннан чакырылган ханым-туташлар катнашкан. Әлбәттә, җәдит кызлар мәктәпләрендә укыткан абыстай-мөгаллимәләр дә булган. Алар барысы да үзләренең эшчәнлеге белән татар җәмәгатьчелегенә билгеле, абруйлы шәхесләр. Шулай да съезд эше белән рус гимназияләрендә һәм Югары курсларында белем алган туташ һәм ханымнар җитәкчелек иткән. Гасыр башыннан бирле хатын-кызларның юлбашчысы саналган Л. Хөсәения кебек мөгаллимә абыстайлар исә, иске карашлы саналмасалар да, шактый радикаль фикер йөртүче зыялы ханым-туташлар янында бераз югалып калган диярлек урын бар.

Съезд дүрт көн дәвамында — 1917 елның 24-27 апрелендә эшләгән. Беренче утырышны Вакытлы мәркәз бюро рәисәсе Х. Таначева ачып җибәргән. «Дөньяда ирләр белән хатыннарның саны якынча тигез, ләкин сәяси, икътисади, иҗтимагый һәм башка бик күп сәбәпләр аларны ирләрдән түбәнәйтте. Әмма хатыннар үз хокуклары, тигезлек өчен гомер буе тырыштылар һәм Аурупа хатыннары зур уңышларга да иреште. Әлегә кадәр без бу хокуксызлыклар турында сөйли алмадык. Иске хөкүмәт бетте, революция безгә хөррият алып бирде. Без төрле урыннарда сөйләшә ала башладык»[11], — дип башлап җибәргән үз нотыгын Русиядәге беренче революция елларыннан ук иҗтимагый һәм милли хәрәкәттә актив катнашып килгән (1907 елда ул «Урал» газетасының рәсми мөхәррире дә булган) Хәдичә ханым. Бөтенрусия мөслимәләренең беренче съездына җыелган

вәкиләләрне ул Вакытлы мәркәз бюро башкарган эшләр белән таныштырган. «Ике-өч атналык хезмәтебез нәтиҗәсендә без хәзер дөнья яратылганнан бирле беренче тапкыр булган мөслимәләр съездында утырабыз. Мин, мәркәз бюроның рәисәсе буларак, бик шатмын һәм киләчәктә дә мондый съездларның ел саен булуын телим», — дип, Хәдичә ханым съезднең әһәмиятлелеген күрсәткән. «Съездда Мәскәүдә булачак гомуми мөселманнар съездына кертелергә тиеш булган иң әһәмиятле мәсьәләләр генә тикшереләчәк. Ул мәсьәләләр исә: 1) хатыннарның шәригатьтәге хокуклары; 2) хатыннарның гаиләдә тоткан комиссия сайлаганнар. Петроградтан чакырылган Югары Бестужев курсларын тәмамлаган һәм шунда хокук фәлсәфәсен укыткан С. Әхмәрева съездның рәисәсе, Казан хатын-кызлары арасыннан беренче теш табибәсе Х. Таначева һәм Уфа зыялысы, беренче мөслимәләр җәмгыятен оештыручылардан булган Ф. Алкина — рәисә урынбасарлары, Казан югары хатын-кызлар курсларын тәмамлаган М. Гобәйдуллина, Казан Татар укытучылар мәктәбе таныклыгына ия булган З. Салихова, гимназия тәмамлаган Х. Мостафина һәм З. Алиевалар (барысы да мөгаллимәләр) сәркятибәләр итеп билгеләнгән.



Бөтенрусия мөслимәләренең беренче съездында катнашкан вәкиләләрнең фоторәсеме. 1 нче рәт (сулдан уңга): 1. Абруй Сәйфи; 2 нче: 2. Маһирә Мөштәриева, 4. Нәфисә Богданова, 6. Мәрьям Мөштәриева; 3 нче: 1. Әсма Еникиева, 2. Зәйнәп Хәсәнова, 3. Фатиха Аитова, 4. Хәдичә Мостафина, 5. Мәрьям Гобәйдуллина, 6. Фатыйма Адамова, 7. Сара Әхмәрева, 8. Хәдичә Таначева, 11. Әминә Фәезханова; 4 нче: 3. Акъкәгазь Дусҗанова, 4. Зәйнәп Камалова, 5. Заһидә Бурнашева, 9. Әдибә Шәфика, 10. Сәлимә Якупова, 13. Әминә Терегулова, 15. Илһамия Туктарова; 5 нче: 1. Фәхрелбәнат Сөләймания, 14. Мәрвәрид Туктарова; 6 нче: 6. Ләбибә Хөсәенова, 7. Хатимә Камалова. Авторның шәхси архивыннан.

һәм тотачак урыннары; 3) хатыннарның сәяси хокуклары; 4) хатыннарның иҗтимагый тормышта тоткан урыннары; 5) хатыннарның Учредительный собраниегә катнашулары һәм шуны фәгалиятькә чыгару (эшкә ашыру); 6) хатыннарга махсус мәәссәсәләр (оешмалар)»[12], — дигән сүзләр белән Х. Таначева съездның программасын билгеләгән.

Беренче утырышта вәкиләләр съездның эшче органнарын — президиум һәм резолюцияләр хәзерләү өчен биш

С. Әхмәрева тәкъдиме белән хөррият өчен көрәштә корбан булган каһарманнарны, Мәскәү делегациясе исеменнән Х. Камалова тәкъдиме белән татар халкының мәшһүр кызларын — Зөһрә Акчурина-Гаспринская һәм Фатыймаи-Фәридә Нәүрузованы зал аягүрә басып искә алган. Бу утырышта төрле төбәкләрдән һәм оешмалардан килгән котлау телеграммалары укылган, күпсанлы тәбрикләү сүзләре әйтелгән. Мәсәлән, Мөселман комитеты рәисе Ф. Туктаров,

Мөселман хәрби комитеты рәисе И. Алкин үз оешмалары исеменнән съездны тәбрикләгәннәр. Тәбрикләүләр калган утырышларда да дәвам иткән. Икенче мәҗлестә шул ук көннәрдә Казанда эшләгән укытучылар съезды исеменнән тәбрикләү сүзләрен Г. Гобәйдуллин җиткергән.

Утырышлар мәркәз бюро тарафыннан хәзерләнгән докладларны тыңлау һәм эшлекле фикер алышуга багышланган. Барлыгы алты доклад укылган: «Исламда мөселман хатыннарының хокуклары» (М. Туктарова), «Иҗтимагый-сәяси тормышта хатын-кызлар» (М. Мөштәриева), «Хатыннарның иҗтимагый һәм гаиләви хәлләре» (Х. Камалова), «Мәмләкәт корылтаена сайлаулар» (И. Туктарова), «Хатыннарның иҗтимагый тормыштагы урыннары» (М. Мөштәриева), «Милли мәәссәсәләр турында» (М. Мөштәриева һәм З. Бурнашева).

Кызу бәхәсләрдән соң бертавыштан кабул ителгән карарларның иң мөһиме — исламда ир белән хатынның тигез булуын раслаган карар. Махсус комиссия тарафыннан хәзерләнгән бу карар өч пункттан гыйбарәт. Менә алар: «1. Шәригатьтә ир белән хатын бертигез. 2. Шәригатьтә хатыннарның сәяси, иҗтимагый эшләрдә катнашырга хаклары бар, димәк, сайлауга катнаша алалар. 3. Шәригатьтә хатыннарга хиҗап юк»[13]. Иң күп бәхәсләр тудырган бу карар башка карарларга нигез булган. Икенче төркем карарлар хатын-кызларның булачак Учредительный собраниегә сайлауларга катнашу мөһимлеген күрсәткән. Гаиләниках мәсьәләләреңә багышланган өченче төркем карарлар ир һәм хатынның гаиләдәге хокуклары тигез булуын һәм күпхатынлылык бетерелергә тиешлеген билгеләгән.

Тагын бер төркем карарлар хатын-кызларны берләштерү һәм оештыру эшләренә багышланган. Монда Русиядәге барлык мөслимә җәмгыятьләрен берләштерү, аларның эшчәнлеге белән съездда сайланачак Вакытлы мәркәз комитет (бюро) җитәкчелек итәргә тиешлеге хакында әйтелгән. Вакытлы мәркәз комитетның биш кешедән булуы һәм аның эш урыны итеп Мәскәү сайлануы күрсәтелгән. Комитетның матди җәһәтен тәэмин итү өчен төрле җәмгыятьләрдән һәм халыктан акча җыю да каралган. Соңгы утырышта Вакытлы мәркәз бюрога биш кеше — С. Якупова, З. Бурнашева, Д. Булгакова, Р. Солтангалиева һәм Ө. Әсфәндияровалар сайланган. Бюро әгъзалары һәм тагын өч кеше — Х. Таначева, И. Туктарова һәм мадам Киринская — 1 майда Мәскәүдә ачылачак гомуми мөселман корылтаена вәкилә итеп билгеләнгәннәр. Съезд эше тәмамланганнан соң вәкиләләр фоторәсемгә төшкәннәр (съездда катнашканнардан 66 вәкиләне сурәтләгән бу фоторәсемдә татар халкының иң зыялы, иң тәвәккәл, милләт бәхете өчен көрәш сафларына басарга әзер ханым һәм туташларның нурлы йөзләрен күрү безнең өчен дә бик мөһим). Кич белән алар мөслимәләр җәмгыяте файдасына «Сәйяр» труппасы башкарган Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем» әсәрен караганнар.

Татар хатын-кызларының зур корылтайлар уздыру тәҗрибәсе булмаса да, Вакытлы мәркәз бюро һәм съездның җитәкче органнары өсләренә алган эшне уңышлы башкарып чыкканнар. Алар белемдә дә, оештыру эшләрендә дә ирләрдән калышмаганлыкларын күрсәткәннәр. Съезд барышы да үзләре һәм, гомумән, татар җәмгыяте алдында торган көнүзәк мәсьәләләрне хатын-кызларның чишәрлек дәрәҗәдә булганнарын раслый. Матбугатта урын алган барлык күзәтүләрдә дә съездның эше югары бәяләнгән. Мәсәлән, Я. Хәлили мөслимәләр съездына «Сөембикә» журналындагы шактый киң күзәтүендә докладларның тулы һәм югары дәрәҗәдә булуын, фикер алышуда вәкиләләр белән бергә күпсанлы кунакларның да актив катнашуын ассызыклаган. Моңа кадәр бергә җыелмаган-очрашмаган, күп очракта бер-берсе хакында ишетеп-укып кына белгән төрле катлам хатын-кызлары, уй-гамәлләрен берләштереп, бердәм фикергә килә алганнар. Кабул ителгән карарлар съезд вәкиләләренең генә түгел, бөтен Русия мөслимәләренең хатын-кызның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге роленә карашларын шактый тулы чагылдырган.

Съездда катнашкан вәкиләләр исемлеге*:

Абызгилдиева Гайшә (Уфа), Агафурова Сәлимә (Екатеринбург), Адамова

* Исемнәр төрле чыганаклардан җыелды.

Фатыйма (Оренбург), Аитова Фатиха (Казан), Акимбәтева Мәрьям (Казан), Акчурина Бәдриҗиһан (Зөябаш, Сембер губерниясе), Акчурина Зөһрә (Гурьевка, Сембер губерниясе), Алиева Зәйнәп (Оренбург), Алкина Фатыйма (Уфа), Аричия Мәрьям (Әлмәт), Әдибә Шәфика (Баку), Әсфәндиярова Өммегөлсем (Ташкент), Әхмәрева Сара (Петроград), Әхмәтова Фатыйма (Пермь), Әхмәтханова Рокыя (Пермь), Баязитова Мәдинә (Чиләбе), Батыршина Әминә (Баку), Баһаветдинова Гайшә (Казан), Бикташева Мәрзия (Минзәлә өязе), Богданова Нәфисә (Казан), Булгакова Диләрә (Кырым), Бурнашева Заһидә (Мәскәү), Бәнүзбирия Зәкия (Теләнче Тамак, Уфа губерниясе), Бабичева Зәйнәп (Пороховой, Казан), Габидия Зәкия (Бишбалта, Казан), Габбасова Маһирә (Малмыж), Галишия Фатыйма (Әлмәт), Гафарова Гөлчәһрә (Сембер), Гафарова Зәйнәп (Сембер), Гафурова Факиһә (Чистай өязе), Гобәева Бәнат (Самара), Гобәйдуллина Мәрьям (Казан), Дәүләткилдиева Фатыйма (Казан), Дусҗанова Акъкәгазь (Мәскәү), Еникиева Әсма (Казан), Еникиева Сәгадәт (Ташкент), Иманкулова Ләмига (Гурьевка, Сембер губерниясе), Исмәгыйлева Рабига (Чистай), Йосыпова Нәфисә (Алабуга өязе), Йосыпова Хәдичә (Чиләбе), Камалова Хәтимә (Мәскәү), Камалова Зәйнәп (Оренбург), Карамышева Фатыйма (Мәскәү), Кастрова Гафифәбану (Касыйм), Кастрова Хәдичә (Касыйм), Корбангалиева (Петроград), Криницкая (Киринская-?) Мәрьям (Минск), Коләхмәтева Фатыйма (Мәскәү), Кәбирова Зәйтүнә (Чистай), Латифия Фатыйма (Касыйм), Максудия Зәйнәп (Казан), Мансурия Өммегөлсем (Казан), Мансурова Ркыя (Малмыж), Морадымова Мәрьям (Чистай), Мостафина Хәдичә (Казан), Мөхетдинова Әминә (Казан), Мөхетдинова Мәрьям (Казан), Мөштәриева Маһирә (Оренбург), Мөштәриева Мәрьям (Казан), Нугаева Гөлминур (Мәскәү), Рәфикова Әминә (Бишбалта, Казан), Рәфикова Өммегөлсем (Пороховой, Казан), Рәхманкулова Зөләйха (Саратов), Салихова Зөһрә (Чистай), Сәйфи Абруй (Казан), Сәйфуллина Нәфисә (Зөябаш, Сембер губерниясе), Солтангалиева Рауза (Баку), Сөләймания Фәхрелбәнат (Казан), Таначева Хәдичә (Казан), Таһирова Әкълимә (Самара), Тимбикова Хәдичә (Самара), Терегулова Әминә (Казан), Туктарова Илһамия (Мәскәү), Туктарова Мәрвәрид (Бөгелмә), Усинова Сәрвәр (Бишбалта, Казан), Фәезханова Әминә (Казан), Фәйзуллина Хәйренниса (Мәскәү), Фәйзуллина Шәмсия (Пермь), Хәмидия Фәхрелбану (Чаллы), Хәмидия Хәлимә (Яуширмә, Казан губерниясе), Хәмидия Шәмсеруй (Теләнче Тамак, Уфа губерниясе), Хәсәнова Зәйнәп (Казан), Хөсәения Ләбибә (Казан), Шакулова Сара (Казан), Шәфигуллина Мәймүнә (Троицк), Юнысова Гайшә (Казан), Якубова Мәрьям (Чаллы), Якупова Сәлимә (Баку), Җәббарова Кояш (Мамадыш), Җәгъфәрова Рабига (Пороховой, Казан).

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Каспий. – 1917. – 12 март.
2. Мөселман хатыннарының тавышлары // Сөембикә. – 1917. – № 9. – Б. 142.
3. Шунда ук. – Б. 143.
4. Кояш. – 1917. – 9 апрель.
5. Шунда ук. – 21 март.
6. Шунда ук. – 6 апрель.
7. Шунда ук.
8. Сөембикә. – 1917. – № 11. – Б. 191-192.
9. Кояш. – 1917. – 13 апрель.
10. Хәлили Я. Казандагы гомуми мөслимәләр съезды // Сөембикә. – 1917. – № 11. – Б. 174.
11. Шунда ук. – Б. 167.
12. Йолдыз. – 1917. – 26 апрель.
13. Хәлили Я. Күрс. хез. – Б. 171.

№ 1. Ханымнар съезды

Мөхтәрәмә ханым вә туташлар!

Тиздән Мәскәүдә Бөтенрусия мөселманнарының съезды булачагы һәркемгә билгеле. Һәрбер, азмы-күпме фикере вә аңы булган кеше, хәзерге хәлдән файдаланып, Бөтенрусия мөселманнарының кирәкләрен уйлашырга, җитешмәгән җирләрен җитештерү өчен бергәләшеп киңәшергә шул съездга омтыла.

Без, ханымнар да, шундук үзебезнең хәлләребезне сөйләп, теләкләребезне булдырырга тырышмакчы булабыз. Ләкин хатын-кызның, гаилә тормышында булсын, иҗтимагый вә сәяси эшләрдә булсын, ирләрнекеннән күп үзгәлек бар. Шуңар күрә дә гомуми мөселман съездына кадәрле без, мөселман хатыннары да, бер-берсен аңлашыр өчен бер җиргә җыелышып сөйләшергә-киңәшергә тиеш идек. Шул максатны җиренә җиткерү өчен Казанда Бөтенрусия мөслимәләренең съезды хәзерләнә. Анда сайланып киләчәк вәкиләме, яисә хосусый чакырылачак ханымнармы, үзләренең җирле тормышлары, гадәт-йолалары вә төп теләкләре белән яхшы таныш булып, шул съездга докладлар хәзерләүләре өмет ителә.

Съездда шул хазир булган ханымнарның теләк вә арзуларына карап, һәр яктан бер ноктаи назарга киленер вә шуңар бинаән гомуми мөселман съездына мөселман хатыннарының хәтты хәрәкәләрен хәзерләп кертелер.

Казан кирәк мәдәни, кирәк башка яклардан булсын, уңайлы табылганга, бу съезд да Казанда ясалырга карар кылынып, шундук вакытлы мәркәзи комитет та тәшкил кылынды. Ул комитет, съездны муаффәккыятьлерәк рәвештә чыгару өчен, Русиянең иң ерак почмакларына кадәрле съездның максудын вә кыскача программасын аңлатырлык оешырга чакырып тәфсилле телеграммалар җибәрде.

Съездның кыскача программасы газеталарда да язылып үткән иде. Аңар карап, съездда каралачак мәсьәләләр аз дип уйланылмас, чөнки андагы һәрбер мәсьәлә шәригать ягыннан вә тормышыбызның агымына карап тәфсилле рәвештә төптән тикшерелер.

Кояш. – 1917. – 16 апрель.

№ 2. Казанда 1917 елның 24-27 апрелендә булган мөслимәләр съезды карарлары

(Бөтенрусия мөселманнарының 1917 елның 1-11 маенда Мәскәүдә булган гомуми съезды тарафыннан тулысынча кабул ителгән)

Съезд, хатын-кыз мәсьәләсен тикшергәннән соң, Казанда 24-27 апрельдә булган мөслимәләр съездының 10 маддәле карарын бөтен килеш кабул итте.

I

1) Шәригатьнең хитапларында ир белән хатын бер.

2) Хатыннарның сәяси, иҗтимагый эшләргә катышырга шәригать алдында хокуклары бар, шунлыктан хатыннарның сайлау эшләренә катышулары шәригать буенча да тиеш.

3) Хатыннарга хиҗап шәригатьтә юк.

II

Хатыннары тигез хокуклы булган милләт кенә көчле булып яшәве һәм бу хокукта тигезлекне хатыннарның канун төзи торган мәхкәмәләрдә үзләре хәзер булганда гына фәгалиятькә чыгару мөмкин булганлыктан, мөслимәләр бөтен сәяси хокукта ирләр белән тигез булсыннар. Хатыннар ил корылтаена сайлый һәм сайлана алсыннар.

III

Сайлау-сайлану эшләре мөслимәләр өчен яңа бер эштер. Бердән, хатыннарыбыз моңар кадәр иҗтимагый эшләргә катышырга өйрәнмәгәнлектән, икенчедән, ирләре хатыннарның сайлау урыннарына баруларына каршы тору ихтималы булганга күрә; халкыбызның ярты сы булган хатыннарыбызның тавышлары югалмасын өчен: ил корылтаена сайлаулар вакытында һәрбер мөслимәнең сайлауга катышуы бурыч булсын; мөслимәләргә тавыш бирү өчен ирләрдән аерым урын билгеләнсен.

IV

Русия мөселманнары арасында кыз һәм егетнең ризалыгыннан башка никах уку бик күп булып, бу эш гаилә хәятының тынычсызлыгына вә шул гаиләдә үскән балаларның бәхетсезлегенә сәбәп булганлыктан, никах вакытында кияү белән кыз үзләре хазир булсыннар.

V

Гаиләдә ир белән хатын тату тормаганда күп вакытларда хатын иреннән аерылып китәргә теләсә дә, аны ире аермыйча газаплап тота. Татулыксыз, гаиләдә кысынкы тормышта тору хатын өчен җәбер, гаиләдәге балаларның тәрбиясе өчен зарарлы булганга күрә, съезд, хатыннарның хокукын һәм киләчәк буынның тәрбиясен игътибарга алып, ошбу карарны чыгарды: ошашмаган тәкъдирдә хатынның иреннән аерылып китәргә хакы булуы никах дәфтәренә кертелсен.

VI

Төркестан һәм Кавказда һәм шулай ук Казакъстанда 11-12 яшьлек сабый кызларны кияүгә бирү гадәт хөкеменә кергәнгә, бу эш хатыннарның зәгыйфьләнүенә, вакытсыз үлүләренә һәм зәгыйфь балалар җитештереп, киләчәк буыныбызның зәгыйфь вә көчсезлегенә сәбәп булганга, съезд, Русиянең кирәк шималенда, кирәк җәнүбендә 12 яшьтән ким булган кызга никах укылмасын дигән карарларны чыгарды.

VII

Милләт балалары таза һәм саглам булсын өчен, һәм дә гаилә бәхетсезлекләренең байтагы ир я хатынның йогышлы авыруларга мөбтәля булуыннан килгәнгә күрә, шул бәхетсезлекләр белән көрәшү өчен съезд «никах вакытында кияүнең дә, кызның да йогышлы авырулары булмавына кулларында шәһадәтнамәләре булсын» карарын кабул итте.

VIII

Күп вакыт ирләрнең бер хатын өстенә икенче хатын алуга бер уен төсле генә итеп караулары һәм әүвәлге хатыннарын бер дә гаепсез хәлдә аерып җибәрүләре гадәт булып киткәнлектән, бу эшнең сүэ истигмальларга сәбәп булганлыгын да игътибарга алып, съезд: «никах вакытында кияүнең кулында бер хатын өстенә икенче хатын алмаска язу алынсын, әгәр дә инде бер-бер сәбәп белән икенче хатын алса, карт хатынын аерып, аңар нәфәка бирсен» карарын кабул итте.

IX

Казакъстанда кыз балаларны аталары кечкенәдән үк калым малына саталар, соңгы көндә хатын аерылырга теләсә, калым малын кайтарып бирергә мәҗбүрә була. Бу калым, мәһәрдән башка бер нәрсә булып, кызны атасыннан сатып алганда бирелә торган бер нәрсә. Шул сәбәпле съезд, казакъ кызларының хокукларын игътибарга алып: «казакъ кызлары кияүгә барганда калым малы алу булмасын. Моңар кадәр калым малы алынып куелган казакъ кызлары үз ризалыкларыннан башка әйтелеп куелган кешеләренә бармаска хаклы булсыннар» карарын кабул итте.

X

Күп хатыннар төрле сәбәпләр буенча фәхешханәләргә барып керергә мәҗбүрә булалар. Кайсылары аннан котылырга чаралар эзләсәләр дә, фәхеш турысындагы кануннар сәбәпле алар гомергә бәхетсезлектә калалар. Шул сәбәптән фәхешханәләр һәм фәхеш турысындагы законнар бетерелсеннәр.

Бөтенрусия мөселманнарының 1917 елда 1-11 майда Мәскәүдә булган гомуми съездының протоколлары. – Петроград, 1918. – Б. 354-357.

СҮЗЛЕК:

Арзу — теләк, ният.
Бинаән — нигезләнеп.
Җәнүб — көньяк.
Нәфәка — алимент.
Ноктаи нәзар — караш.
Мақсуд — максат.
Мөбтәля — дучар.
Саглам — сәламәт.
Сөэ истигъмаль — явыз ният белән куллану.
Фәгалият — эшчәнлек.
Хазир булу — катнашу.
Хәтты хәрәкәт — тактика.
Хәят — тормыш, яшәеш.
Шималь — төньяк.

Альта Мәхмүтова,
тарих фәннәре кандидаты

РЕЗЮМЕ

Публикация А. Махмутовой посвящена становлению движения татарок-мусульманок за достижение политических и гражданских прав в 1917 г. В ней описывается история создания общества татарских учительниц, их деятельность по активизации женщин-татарок Казани и страны в борьбе за свои права. Особое место уделено истории созыва и работы Первого Всероссийского съезда мусульманок (Казань, 24-27 апреля 1917 г.). К статье прилагаются список участниц съезда, фотография делегаток и документы.